ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2022 Балык Бистәсе штп. №400пи

Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген раслау турында

"Террорчылыкка каршы көрәш турында" 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 6.1 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр күпләп җыела торган урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы сакланышына таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспортлары формаларын раслау турында» 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына туры китереп карар бирәм:

1.Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген раслау турында» 2019 елның 03 апрелендәге 120пи номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз җаваплылыгымда калдырам.

Житәкче вазифаларын башкаручы Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2022 елның 29 декабрендәге 400
пи номерлы карары белән
расланган

**Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеге**

| № п/п | Кешеләр күпләп була торган урынның атамасы | Кешеләр күпләп була торган урын адресы | Кешеләр күпләп була торган урын категориясе |
|---|---|---|---|
| 1 | Иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемалар буенча җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен махсус билгеләнгән яисә җайлаштырылган урын Балык Бистәсе штп., Яр буе ур. | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, Яр буе ур., | 3 |